**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Рәисе премиясен бирү комитеты составына үзгәрешләр кертү турында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясен гамәлгә кую турында» 2015 елның 3 июлендәге ПУ-619 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 4 июнендәге ПУ-503 номерлы, 2017 елның 3 июнендәге ПУ-460 номерлы, 2018 елның 27 гыйнварындагы ПУ-109 номерлы, 2018 елның 17 ноябрендәге ПУ-778 номерлы, 2020 елның 21 июлендәге ПУ-432 номерлы, 2020 елның 25 ноябрендәге ПУ-778 номерлы, 2021 елның 21 июнендәге ПУ-503 номерлы, 2022 елның 8 июлендәге ПУ-470 номерлы указлары һәм Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 19 июнендәге 412 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Рәисе премиясен бирү комитеты (алга таба – Комитет) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комитет составыннан И.Ф. Бәдриевны, Д.Д. Шуваловаңы, К.Г. Яковлевны чыгарырга;

б) Комитет составына кертергә:

Вәлиуллин Ренат Нәкыйф улын – «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясе» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе урынбасары – «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясе» төбәк иҗтимагый оешмасы Советы Башкарма комитеты җитәкчесен (килешү буенча);

Сабурская Алина Викторовнаны – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсе башлыгын;

Шихобалов Валентин Викторовичны – «Татарстан Республикасы Яшьләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директорын (килешү буенча);

в) Комитет әгъзалары вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

И.А. Александровскаяның – «Казан шәһәре Совет районының «А.С. Пушкин исемендәге 93 номерлы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры, «Татарстан Республикасының

рус милли-мәдәни берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасы идарәсе рәисе, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет әгъзасы (килешү буенча)»;

Т.Р. Кадыйровның – «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе урынбасары, «Татарстанның Халыклар дуслыгы йорты» дәүләт бюджет учреждениесе директоры, «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясе каршындагы Татарстан халыклары Яшьләр ассамблеясе» төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасы рәисе, Комитет рәисе урынбасары (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2024 ел, 08 июль
№ 522